**ГЛАВА**
**Кадыбашского сельского поселения**
**Агрызского муниципального района**
**Республики Татарстан**

**Татарстан Республикасы**
**Әгерҗе муниципаль районы**
**Кадыбаш авыл җирлеге**
**БАШЛЫГЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

02.11.2023 Кадыбаш авылы № 2

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кадыбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Кадыбаш авылында гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьялары, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кадыбаш авыл җирлеге Уставының 14 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кадыбаш авыл җирлеге Башлыгы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кадыбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Кадыбаш торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын 2023 елның 16 ноябрендә 13 сәгать 00 минутка билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кадыбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Кадыбаш торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын 2023 елның 16 ноябрендә 14 сәгать 30 минутка билгеләргә.

3. Халык исемлеген территориаль билгеләр буенча бүләргә:

-1 этап: Кадыбаш авылы Гали ур., Касай ур., Клуб ур. халкы

-2 этап: Кадыбаш авылы Тау асты ур., Совет ур. халкы.

4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны түбәндәгечә расларга: “2024 елда үзара салым акчаларын кертү өчен «Кадыбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Кадыбаш авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 700 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертүгә, I төркем инвалидлардан, студентлардан тыш, көндезге формада белем алучы гражданнардан, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны (хәрби хезмәткәрләрне, мобилизацияләнгән, ирекле киткән) һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатыннарын, балигъ булмаган балаларын) түләүдән азат итү һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юллау белән килешәсезме:

1. Урамнарны яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр

энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка мәйданчыкларны ремонтлау:

1.1 лампалар, дроссельләр, фонарьлар сатып алу һәм алмаштыру;

1.2 электротоварлар сатып алу;

1.3. урамнарны яктырту өчен материаллар сатып алу;

2. Су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алу, аларны чистарту, транспортировкалау һәм су агызу системаларын, су башняларын, скважиналарны һәм башка инженер корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау:

2.1 су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алу мөмкинлеген тәэмин итүче су манараларын су белән тәэмин итү системасын ремонтлау һәм су бүлеп бирү өчен материаллар сатып алу;

2.2. җирлекне су белән тәэмин итүне тоту (тирән насослар сатып алу һәм ремонтлау, суүткәргеч челтәрен ремонтлау)

3. Янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү:

3.1 янгын сүндерү машинасы өчен ягулык-майлау материаллары сатып алу;

3.2 янгын сүндерү машинасы өчен автозапчастьләр сатып алу;

4. Халыкның күпләп ял итү урыннарын төзү, ремонтлау һәм алар тирәсендәге территорияләрне төзекләндерү:

4.1 рөхсәтсез чүплекләрне бетерү;

4.2 авыл җирлегенең керү аншлагларын сатып алу һәм ремонтлау, аншлаг ясау өчен торбалар, профильле торбалар, металлар, буяулар, саморезлар һәм электродлар сатып алу;

4.3 Кадыбаш авылында тракторга дизель ягулыгы, дизель мае, ягулык-майлау материаллары һәм запас частьләр алу тракторын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү;

4.4 трактор арбасы сатып алу;

4.5 Кадыбаш авылы үзәгендәге хуҗасыз участокларда коймалар өчен төзелеш материаллары сатып алу;

«РИЗА» «КАРШЫ».

5. Гражданнар җыенын түбәндәге адрес буенча уздырырга: Татарстан Республикасы, Әгерҗе районы, Кадыбаш авылы, Клуб урамы, 49 б йорты, авыл мәдәният йорты.

6. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кадыбаш авыл җирлеге башкарма комитетына гражданнар җыенын оештыруны һәм уздыруны йөкләргә.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кадыбаш авыл җирлеге мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (https://www.agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru).

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Башлык Х.Л. Закиров